Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм әйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2:256)

# Ислам нуры

بسم الله الرحمن الرحيم

№ 24 (652) 25 декабрь, 2017 ел (1439, Рабигул-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫ БЕЛӘН

Чаллы шәһәренең концертлар залы нинди генә кичәләрне, нинди генә артистларны, тамашачыны күрмәгәндер. Мәүлид кичәсенә багышланган шәһәркүләм чара — шау-шулы, ыгы-зыгылы тамашалардан аермалы буларак, зал тутырып килгән тамашачыга әхлак тәрбиясе бирүе белән үзенчәлекле иде. Әлеге чараның күңелне айкаган, җанны тынычландырган, сафландырган Коръән аятьләре белән башлануы үзе үк күп нәрсә хакында сөйли. Коръәнхафиз, РИИ мөгаллиме Микадәм хәзрәтнең моңлы тавышы тамашачыны рухи яктан шундый ук аерым бер дулкынга “көйләп куйгандай” итте. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәүлид уздыруның саваплы гамәл булуын Коръән аятьләре һәм хәдисләр белән җыйнак, мәгънәле итеп аңлатып үтте. Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Хәлимов кичәдә катнашучыларны Мәүлид ае белән котладылар. Мөхтәсибәтнең “Хәзинә” балалар клубы — бүгенге болгавыр чорда бик күп яшьтәшләренә, аларның әти-әниләренә үрнәк итеп күрсәтерлек гамәлләре белән һәрдаим сөендерep тора. Бу чарада да әлеге мөселман клубына йөрүче балалар пәйгамбәребезгә (с.г.в.) багышланган тамаша күрсәтеп сокландырдылар. Шәһәрнең яшь имамнары Илназ хәзрәт Яхин, Мөхәммәд хәзрәт Мөхәммәтовның кыска, әмма бик тә эчтәлекле кыйссаларын, Кукмарадан килгән кунакларның мөнәҗәтләрен, алып баручы Румил Кәрамиевнең зәвыклы сөйләмен тыңлагач: “Их, башка кичә-концертларда еш кына колак әзелеп тешәрдәй мәгънәсез юмор сөйләүчеләргә, очсызлы җырга үрле-кырлы сикерүчеләргә, шуларны алкышлап утырган тамашачыларга менә кемнәрне тыңлатырга иде”, - дип күңелдән генә ах итеп куясың...







Рабигул-әүвәл аеның соңгы көннәрендә оештырылган бу кичә Мәүлид ае белән саубуллашу чарасы да иде. Алдагы елларның да шушындый матур бәйрәмнәрен мәгънәле итеп, күңел җылысы белән үткәрергә язсын!

## Ризыгың хәләл булсын...

Россия ислам институтында хәләл продукцияне җитештерү өлкәсендә Техник комитетның утырышы узды. Комитетның төп максаты булып продукцияне җитештерүдә һәм “Хәләл” хезмәтләр күрсәтүдә гомумфедераль стандартлаштырылган методларны эшләү һәм гамәлгә кертү тора. “Бүгенге көндә “Нәрсә ул хәләл?” дигән сорауга еш кына “Дуңгыз итен кулланмау” дип җавап кайтаралар. Җәмгыятьтә мәсьәләне төптән аңлау юк. Безнең өчен тегe яки бу продукциянең “хәләл” дип аталганлыгын түгел, ә бәлки аның хәләл булуын ачыклау мөһим. Безгә продуктның асылы әһәмиятле. Без, беренче чиратта, кулланучыларның хокукларын кайгыртырга тиеш”, — дип белдерде мөфти хәзрәтләре Техник комитет утырышының ачылышында.

Утырыш эшендә төбәк Диния нәзарәтләреннән 53 вәкил катнашты, Татарстан, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан, сөт һәм ит промышленносте фәнни институтларыннан, “Хәләл” сертификацияләү комитетларыннан һәм үзәкләреннән, җитештерүче предприятиеләрдән вәкилләр килде.

### Яңа мәчет



Яшел Үзәндә Җәмигъ мәчете ачылды. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, район башлыгы Александр Тыгин, район имам-мөхтәсибе Габделхәмид хәзрәт Зиннәтуллин, республикабыз һәм Россия төбәкләренең дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, шулай ук Яшел Үзән мөселман өммәте вәкилләре, Җәмигъ мәчет төзелешенә актив өлеш кертүчеләр катнашты.

### Мәрҗани елына әзерлек



Бөтендөнья җәмәгатьчелеге һәм мөселман дөньясы 2018 елның гыйнварында татар дин галиме, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең 200 еллыгын билгеләп үтәчәк. Шуңа бәйле рәвештә, Арча районының Ташкичү авылында Ш.Мәрҗани музее, аңа багышланган комплекс һәм аның исеме белән аталган Мәрҗани чишмәсе, Арча районы Симетбаш авылында яңа мәчет ачылу тантаналары булып узды.

### Мәгънәле сөйләшү

Чаллы шәһәре имамнарының чираттагы җыелышы булды. Анда дини матбугатка язылу, шәһәр күләмендә уздырылучы Мәүлид кичәсендә актив катнашу, мәчетләрдә иске имля дәресләрен башлау, теләүчеләр өчен татар телен өйрәнү курслары оештыру турындагы сораулар күтәрелде, башка мәсьәләләр дә каралды. Мәсәлән, “Чаллы-Бройлер” кошчылык фабрикасында тулысынча хәләл җитештерүгә күчү сәбәпле, андагы эш барышын тәүлек әйләнәсендә күзәтүгә шәһәр имамнарын да тарту турында; яшь парларга, алар белән дәрес үткәрмичә, никах укымау хакында карарлар кабул ителде; татар телен үстерү концепциясе белән танышу булды.

* * *

Чаллы мөхтәсибәте каршында эшләп килүче “Хәзинә” мөселман балалар клубында игелекле чаралар еш үтә. Әле күптән түгел генә бертөркем малайлар, Илгиз хәзрәт һәм Сәлмән хәзрәт белән бергәләп, кошлар өчен бик күп итеп җимлекләр ясадылар. Беренче карашка гади генә тоелган мондый күренешләр яшь буынга әхлак тәрбиясе бирүе, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар тәрбияләве белән игътибарга лаек.

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН**

# Ахырзаман галәмәтләре...

Кечкенә вакытта әбиләребез: “Ахырзаман алдыннан тимер кошлар очар, өйдә җансыз кешеләр сөйләр, адәмнәрнең ояты китәр”, - дип сөйли иделәр. Каршыларына оныкларын утыртып, хикмәтле абыстайларыбыз көннәрдән бер көнне дөньяның бетәсен, бөек хөкем көненең киләсен, кешеләрнең кылган гамәлләре өчен җавап тотасын кечкенәдән күңелләренә сеңдереп, иман орлыкларын салып калырга тырышканнар. Бәлки, ул галәмәтләрнең кайберләрен әби-бабайларыбыз үзләре дә күреп бетермәгәндер. Чыннан да, моннан күп еллар элек яшәгән Пәйгамбәребез Мөхәммәд гади кеше булмаган, ул Аллаһтан килгән гыйлем белән киләчәктә ниләр буласын, ахырзаманда кешеләрнең нинди җәмгыятьтә яшәячәген әйтеп калдырган. Бу аның бер яктан хак Пәйгамбәр икәнен күрсәтсә, икенче яктан безгә Кыяммәтнең киләсен, дөнья тормышының туктаячагын һәрдаим исебезгә төшерә.

Ахырзаман галәмәтләре еллар, гасырлар дәверендә ил һәм шәһәрләребезгә, хәтта юлсыз авылларга да килеп, дөньяның бетәчәген кешеләрнең исләренә төшереп торачак. Без дә ул галәмәтләрне белергә, Раббыбыз янына кайтырга әзер булырга, үзебездән соң киләчәк буыннарга да аларны сөйләргә тиешбез.

Кыямәт галәмәтләре хакында Пәйгамбәребез әйтеп калдырган йөзләрчә хәдисләрнең берсен генә китерәсем килә. Бу сүзләрне укыгач, кайсыгыз: “Юк, мин бу сүзләр белән килешмим, минем мондый хәлләрне күргәнем юк”, - дияр икән? Моннан 14 гасыр элек әйтелгән сүзләрне без көн саен үз илебездә, шәһәр һәм авылыбызда, гаиләләребездә һәм үзебездә күреп торабыз.

Әбү Һурайраның тапшыруынча, Пәйгамбәребез әйтте: “Аллаһыдан кешеләргә бүләк итеп бирелгән малны аерым кешеләр үз араларында кулланырлар”... Аллаһ Тәгаләдән халыкка бүләк булып килгән нигъмәтләрне аерым шәхесләрнең үзара бүлешеп, үзләре өчен генә кулланулары гаделсезлек булып тора.

— “Әманәтне ганимәт итәрләр”... Әманәт - вакытлыча, саклап тору өчен бирелә торган нәрсә, һәм ул синеке түгел. Еш кына кеше нәрсәнедер алып тора һәм вакытлар үткәч: “Бу минеке түгелме соң?” - дип үз малына әйләндерә. Пәйгамбәрнең хәдисендә әйтелгән әманәт сүзе мал-мөлкәт белән генә чикләнми, аның мәгънәсе күпкә киңрәк. Әманәт - ул сиңа ышанып тапшырылган мал, дәрәҗә, вазыйфа һ.б.

— “Зәкәтне мәҗбүри салым кебек күрерләр”... Зәкәтнең төп максаты — кешенең малын һәм җанын пакьлау. Мал иясе зәкәтен үзенең малы дип түгел, фәкыйрь-мескеннәрнең өлешен кайтарам, дип бирергә тиеш. Зәкәт кешенең күңелен комсызлыктан, саранлыктан тазарта. Дөньяны артык сөю бәласеннән коткара. Үзеңнән түбәннәрне күреп, Раббыңа шөкер итәргә булыша. Әмма, ахырзаман җиткәч, иман ияләре зәкәтләрен киң күңел белән түгел, бәлки тиеш булганга, яки өстән кушканга гына бирерләр. Кайсы байның шатланып налог түләгәнен күргәнегез бар? Кызганыч, ахырзаман алдыннан кешеләрнең садәка һәм зәкәтләре дә шул салым түләүгә әйләнер.

— “Гыйлемне дин өчен алмаслар”... Монда сүз дини гыйлем турында бара. Динне өйрәнүчеләр Аллаһка якынаю, үзен төзәтү өчен түгел, үзара мактанышу, үзенең белдекле булуын күрсәтү өчен гыйлем алырлар. Пәйгамбәребез: “Кем гыйлемне наданнар белән сүз көрәштерү, галимнәр каршында “мин дә галим”, дип мактану, кешеләрне үз авызына карату өчен алса, аңа ут, аңа тәмуг булыр”, - диде. (Ибн Мәҗәһ).

— “Ир үзенең хатынына итәгать кылыр, әмма әнисен рәнҗетер”... Күпме ир-егетләр, хатынына ярыйм, дип, газиз әнкәйләрен рәнҗетәләр. Хатыннарыгызны санламагыз димим, әмма хатын көйлим дип, әниеңнең рәнҗешен алу ярамас. Пәйгамбәребез: “Ахырзаман алдыннан кол хатын үзенең хуҗасын тудырыр”, - диде. Әүвәлге заманнарда ата-ана дәрәҗәсе зур булган. Балалар, бүгенге көндәге кебек, үзләрен үстерүче, кеше итүче ата-анасына тавыш, кул күтәрү түгел, хәтта күз дә күтәрергә оялганнар. Әти-әнигә иң күркәм рәвештә эндәшә торган булганнар. Әмма бүген, күпме ата-ана үзенең баласының колы булып, баласына сүз дә әйтергә куркып яши. Татар халкы бабайларның гасырлар буе матча өстендә торган сыек чыбыгын “искелек калдыгы” дип ташлап, Монтессори методикаларына күчкәч, шуңа барып җиттек инде.

— “Дустын якын күрер, атасын ерагайтыр”... Кеше үзенең иптәшләрен, дусларын газиз атасыннан якын күрер. Алар белән серләшер, әтисе белән серләшмәс. Көннәрен һәм төннәрен дуслары хозурында үткәрүне сөеп, олыгайган әтисе белән бер сәгать сөйләшеп утырырга да вакытын кызганыр. Дусты шалтыратса, елмаеп, матур итеп эндәшер, әтисе шалтыратса, чыраен сытып, тавышын тупас кылыр. Һичбер дустың газиз атаңнан да якын, хөрмәтле була алмый.

— “Мәчетләрдә тавышлар күтәрелер”... Кешеләрнең күңелләрендә Аллаһының йорты булган мәчетләргә карата хөрмәт бетәр. Күңелләргә тынычлык ала торган мәчетләрдә тавыш чыгарырлар, ызгыш һәм фетнәләр булдырырлар. Бер бабай: “Шунда барып, көненә бер тавыш чыгарып кайтмасам, йоклый алмыйм”, - дигән ди бит. Дөньяның ыгы-зыгысыннан туеп, тынычлык алыйм дип, мәчеткә килгән кеше анда да тавыш, талаш күрергә тиеш түгел. Мәчеттә тавыш күтәреп сөйләшү зур әхлаксызлык булып тора.

— “Халыкның җитәкчесе ул халыкның бозык кешесе булыр. Юлбашчы итеп иң түбәне куелыр”... Асылда, халыкның башлыгы итеп иң намуслы, иң иманлы, иң гыйлемле, иң лаеклы кеше куелырга тиеш. Пәйгамбәребез, шәһәрләргә башлык итеп, иң иманлы, Аллаһтан иң куркучы кешеләрне билгели торган булган. Ышанырсызмы-юкмы, кайвакыт шәһәр әмирләре ул шәһәрнең мохтаҗ кешеләре исемлегендә торган. Хәзер исә, күп җирдә югары урыннарга малы күп, дуслары көчле булу сәбәпле киләләр. Иманлы, намуслы кешегә җитәкче булу бик авыр. Булса да, шактыйлары озак түзә алмый.

— “Кешегә аның явызлыгыннан куркып кына хөрмәт күрсәтелер”... Кешенең кемгә дә булган хөрмәте, иң элек, аның күңеленнән чыгарга тиеш. Пәйгамбәребезне аның гаделлеге, рәхимлеге өчен яраттылар. Әмма бүген күпләргә карата тыштан хөрмәт күрсәтсәләр дә, эчтән аны күрә алмыйлар. Хөрмәт итмәсәм, зыяны тияр, эштән куар, - дип кенә яшиләр. Бабам исән булганда әйтә иде: “Улым, ул эштән киткәнемә илле ел. Пенсиягә чыкканга утыз ел үтте, хәзер дә урамда шул эшчеләрем мине килеп кочаклыйлар”. Җитәкчегә булган хөрмәтнең чынмы яки тыштан гынамы булуын ул урыныннан төшкәч кенә күреп була.

— “Җырчы хатыннар һәм музыка артыр”... Элек татар сәхнәсенә менгән, җырлаган һәркемне исемләп белә иделәр. Хәзер бөтенесе җырчы, бөтенесе сәләтле. Бу күренеш халыкта җитдилек сыйфатлары кимеп, күбрәк уен-көлке, җыр-бию белән яшәүләрен күрсәтә. Нишләптер, күп әти-әниләр үзенең баласында сәхнә белән бәйле сәләтләр эзли, әмма бүген сәхнәләрдән тыш бакчаларда күпме тәрбиячеләр, мәктәпләрдә укытучылар, басуларда игенчеләр, заводларда осталар, хастаханәләрдә табиблар җитми.

— “Хәмерләр эчелер”... Бүгенге көндә кешелеккә бөек зыян булган терроризм, наркомания, СПИД кебек афәтләргә каршы күпме көрәш алып барыла. Әлхәмдүлилләһ, көрәш чаралары да кирәк. Әмма ул нәрсәләрнең корбаннарын барысын бергә кушсаң да, бу яшел елан аракының корбаннары кадәр булмый. Рәсәйнең ел саен 50 мең кешесе эчеп үлә, исерек килеш руль артына утырып, күпме юл фаҗигалары килеп чыга, күпмеләрнең йөрәкләре аракыга түзә алмыйча туктый, күпме кан коюлар һәм башка афәтләр килеп чыга — анысын бер Аллаһ белә. Пәйгамбәребез: “Кешеләр хәмергә башка исемнәр кушып эчерләр”, - диде. Сыра, шәраб, шампан, ликер, джин һ.б. “Бу бит аракы түгел, сыра гына”, - дип, ата кеше баласына шешә суза. Хәмернең бер тамчысы сәбәпле, Аллаһ кешенең иманын кырык көнгә салдырып ала.

— “Өммәтнең ахыр кешеләре әүвәлгесен ләгънәт кылыр”... Элек яшәгәннәрне “алар - искелек калдыгы”, алар надан булган, - диярләр. Элеккеләр гугл белән яндексларны белмәсәләр дә, без аңлый алмаган күп нәрсәләрне яхшы белгәннәр. Кызганыч, бүгенге көндә заманча мөселманнар арасында да әүвәлге мөселманнарга карата кимсетеп карау юк түгел, хәтта сәхабәләргә, табигыйннарга һәм мәзһәб галимнәренә дә тел тидерәләр.

Бу - пәйгамбәребезнең ахырзаман алдыннан булачак хәлләр хакында әйтеп калдырган хәдисләренең берсе генә. Әмма бу хәдистә һәрберебез үзенең күршесен, дустын, җитәкчесен, иң мөһиме, үзен күрми калмагандыр. “Килер шундый заманнар, иманлы, динле булу - кулыңда утлы күмер тотудан да авыр булыр”, - дигән пәйгамбәребез. Раббым безгә ата-бабаларыбыз 11 гасыр саклап килгән утлы күмерне сүндермичә, иманлы, динле, намуслы халык булып яшәргә насыйп итсен.

## СОРАУ-ҖАВАП

Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга шәригать белгече **Рәфыйк хәзрәт Миннәхмәтов** җавап бирә:

**Әссәламугаләйкум!**

**Хөрмәтле редакция, алдагы саннарның берсендә Коръәннең бер генә аятен инкарь иткән кешегә оеп намаз укыган кешенең намазы дөрес булмау турында әйтелгән иде. Мөртәт булган кешенең укыган намазы дөрес була микән? Мәсәлән, җәмәгать намазы, женаза намазы һәм башка шундый намазлар диюем.**

**Мөдәрис Хаҗиев,**
**Сарман авылы.**

(***Редакциядән: Хат авторының стиле сакланды***).

– Мөртәт кем ул? – Белә торып, аңлап, Коръән аятьләрен инкарь итүче. Ул диннән чыгып китә, димәк, аның намазы дөрес булмый. Әгәр инде тәүбә кылып, кабат иман китерсә, намазы дөрес була. Иман китермәсә, намазы батыл дигән сүз, кабул ителми.

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән*

# Йөрәк бабай һәм падишаһ

*(Хикәят. Төрекчәдән Фатих Кутлу тәрҗемәсе. Ахыры.)*

ҖАҺИТ ЗАРИФОГЛУ

Падишаһ җитди, калын тавыш белән:

— Синең нинди теләгең бар? — дип сораган.

— Саулыгыңны телим. Һичбер үтенечем юк.

— Берәр нәрсә сорарга килдеңме?

— Бер нәрсә дә сорамаска дип килдем. Карасам, монда чын мохтаҗлар гына. Минем берәр теләгәнем булса, аны да боларга бир, дияр идем.

— Синең исемең ничек, бабай?

— Минем исемем Хасан.

— Бары тик Хасан гынамы?

— Хасан да дип әйтәләр, Йөрәк Хасан да, Йөрәк бабай дип тә...

Падишаһ, таудагы сөйләшүнең бермә-бер кабатланганын күреп сөенгән һәм көлеп тә җибәргән. Бабай да хәлне аңлап алгандыр дип уйлаган. Ләкин караса, Йөрәк бабай сафлардан да саф күңелле. Ул падишаһны таный алмаган. Ул падишаһның киемен алыштырып халык арасында йөргәнен каян белсен?

Аның мондый булуы падишаһны тагын да сөендергән.

— Әйдә, Йөрәк бабай, әйт әле — нәрсә телисең, шуны бирәм.

— Саулык-сәламәтлегегезне телим. Сезнең саулыгыгыз булсын, минеке булмаса да мөһим түгел, Мөхәммәт өммәтенә иң элек Аллаһ, Пәйгамбәр, аннары Сез кирәк.

Падишаһ таудагы сөйләшүне Йөрәк бабайның исенә төшерүен һәм бер дөялек акча соравын тели иде. Әмма Йөрәк бабайның исенә төшми икән.

— Хаҗәтең булмагач, нишләп монда басып тордың?

Йөрәк бабай теге көндә булган хәлне сөйләп биргән: "Ул зат миңа, падишаһка бар, аны күр, дип әйтте. Падишаһ сине кабул итәр, сараена алып барып сыйлар. Һәм анда сине бүләкләр, диде."

— Алай булгач, мин дә сине сарайга алып барып, сый-хөрмәт күрсәтим. Аның сүзе һавада эленеп калмасын.

— Юууук, сез нәрсә, падишаһым! Мин бит бары тик аның сүзләрен җиткерер өчен генә сөйләдем. Вакытыгызны минем өчен әрәм итмәгез.

— Нинди әрәм итү булсын. Безгә синнән файда гына булыр. Әйдә, хәзер намаз укырга керик. Хәзер азан әйтәләр. Минем янымда гына бул, еракка китмә, яме?

Гөрләп азан яңгыраган. Намаздан, тәсбих тартудан соң дога кылырга чират җиткән. Падишаһ белән бергә барлык халык кулларын күтәреп Аллаһтан сорый башлаган.

Беравык Йөрәк бабай падишаһның догасын колак салып тыңлагач, аның шулай ялваруын ишеткән:

— И Раббым! Син беркемгә мохтаҗ булмаучы, чын байлык иясе, бәндәләреңә мул итеп бирүче кәримнәрдән дә кәримсең. Безгә бик шәфкатьле, рәхимлесең. Олыларның олысы Син. Миңа ризык бирүче, саулык-сихәт бирүче Син!

Бу сүзләрне ишеткәч, Йөрәк бабай үзалдына: "Моның да кулында бернәрсә юк икән. Ә мин аннан сорарга дип килдем. Күр әле, ул үзе дә бүтән бер падишаһтан сорый. Мин исә аның сараена барырга ризалаштым, дөрес эшләмәдем. Тиз генә моннан чыгып, чатырга кайтыйм әле. Юл буенча агачлар, чәчәкләр, һава белән серләшеп, барлык хаҗәтемне Аллаһыма сөйләп бирим. Бары тик Аннан гына сорыйм",

Йөрәк бабай кабаланып мәчеттән чыккан.

Падишаһ дога кылганда, Йөрәк бабайның башын сузып тыңлаганын чамалады һәм аның ашыга-ашыга торып чыгып киткәнен дә күреп калды. Бер дә дәшмәде. Ул Йөрәк бабайның изге кеше икәнен белде. Шуңа күрә аның ни өчен торып китүен аңлады. Бу юлы догасын үкенүләр белән тутырып, күзләреннән яшь агызып, Аллаһка өр-яңа рух белән ялвара башлады.

Айшә әби, караңгы төшәр-төшмәс, калын агач таягын җилкәсенә күтәреп каршы чыккан. Йөрәк бабай белән Айшә әби чатыр янына кадәр бергәләп атладылар. Бергә ашадылар, эчтеләр. Намазларын кылдылар, догаларын укыдылар. Иртәгесе көн әйберләрен җыйдылар. Һәм аларның җиңелен, авырын бүлеп, аркаларына күтәрделәр. Әкренләп юлга чыктылар. Һәм кичә сөйләмәгәннәрен иркенләп юлда сөйләшеп бардылар.

Әле юлның дүрттән берен дә үтә алмадылар. Икесе дә арып, алҗап, йөкләрен җиргә бушаттылар. Бер-ике сәгать урыннарында сулышлары кабып кыймылдамыйча утырдылар. Тик, намаз кылу өчен хәл кереп, җанланып кузгалдылар.

— Хатынкай, - диде Йөрәк бабай. — Алда тагын юл бар барын, ләкин адым атларлык хәлебез калмады бит. Бу тирәне бик яхшы белеп бетермибез. Тирә-юньдә су бар микән? Шунда туктыйкмы әллә, дим?

— Яхшы булыр, бик тә яхшы булыр, - диде хатыны.

Караштыра торгач, чатыр корыр өчен бер җирне ошаттылар. Бераз ял иткәннән соң, чатыр өчен казык кагарга һәм чатырның җепләрен бәйләргә тотындылар. Соңгы казыкка чират җиткәч, кагып кына булмый бит казыкны. Җепнең сузыласы җире билгеле. Ни бер карыш тегендә, ни бер карыш монда кагып булмый казыкны.

— Хатынкай, - диде карты. — Шул кәйләне бир әле, монда бер таш чыкты. Алланың хикмәтедер инде, ватып, урынына казыкны кагыйм әле.

Йөрәк бабай ташны урыныннан алыр өчен берничә мәртәбә кәйлә белән суккач, алтын тулы казан, кыйммәтле ташлар чыкты. Бу хәлне күргәч, аптырап калдылар. Казанны бөтенләй чыгарып капкачын ачуга, бик күп хәзинәне күреп, шаккатып тынып калдылар. Кояш баерга тора иде. Йөрәк бабай ашыгып әзерләнде. Агач таягын кулына тотты да:

— Гүзәл хатыным, - диде. — Бары тик Аллаһтан гына сорасаң, Ул мул итеп бирә. Ләкин бу кадәрле йөк һәм моның хәтле байлык була торганда йоклап төн үткәрсәк, белеп тор: башыбыз бәладә. Йоклап уянмавыбыз бар. Аннары Аллаһ бездән: "Шуның кадәр байлыкны нишләттегез?" — дип сораса, ни дип җавап бирербез? Шуңа күрә хәзер үк шәһәргә төшәм. Гарип-горәбәләрне җыеп китерәм. Һәрберсенә өләшеп чыгам.

Һәм шулай итеп, Айшә әбинең догалары белән, Йөрәк бабай юлга кузгалды.

Айшә әби намазлыкка утырды. Аның йөрәге бу авыр җаваплылык алдында дерелдәп тора иде.

Айшә әби иртәгәсен Йөрәк бабай әлкәнең иң фәкыйрьләреннән оешкан зур халык төркеме белән күренгәнче урыныннан тормады. Аларны күрүгә, шөкерләр әйтә-әйтә торып басты. Сөенә-сөенә туры Йөрәк бабайга таба йөгерде.

Караса, ул кечкенә бер дөякәй сатып алган икән. Җиленнәре сөт белән тулы дөякәй. Йөрәк бабай юлда аңа атланырга кыймаган. Бавыннан тотып алып кайткан һәм "Ничек сөенер инде!" дип, самими елмаю белән Айшә әбигә карап тора иде...

*Безгә язалар*

# Җирдәге тормыш – ахирәткә әзерлек

Хөрмәтле "Ислам нуры" редакциясе! Тошләрнең хикмәте турында сезгә дә язып җибәрергә булдым.

Земфира — Чаллы кызы. Әнисе Шәмсенур апа биш бала тудыра. Дөньяның болгануы сәбәплеме, башкамы — дин тотмый, намаз укымый. Дөресен генә әйткәндә, атеист була. Озак яши, 92 яше тулганда нык кына авырып китә. Үлем чире икәнлеге ачыклана. Земфираның ничек күңеленә килгәндер: "Әни, анда баргач, безгә хәбәр бирерсең әле нәрсәләр кирәген", - ди әнисенә.

Бер ел үткәч, вафат булган әнисе төшенә керә. Имеш, 3 кыз туган телевизор карап утыралар. Әниләре телевизорда иелә дә бөгелә — намаз укый. Кызлар шаккатып: "Кара әле, үз гомерендә бер намаз да укымаган әни кай арада намаз укырга өйрәнде икән?" - диләр. Әнисе Земфирага карый да: "Кызым Земфира, без бөтенләй дә дөрес яшәмәгәнбез, монда намаз кирәк, намаз кирәк, намаз кирәк икән бит", - ди.

Йокыдан торгач, ахирәттә иң кирәкле нәрсәнең намаз булуын аңлый алар. Өчесе дә берәм-берәм дин юлына баса. Земфираның хәзер шәкертләр укытырлык белеме бар.

Тагын бер очрак, анысы Гөлия белән бәйле. Гөлия — тегүче. Аның исә төшенә әбисе керә. Имеш, карчыклар бар да намаз кылмәкләреннән: "Духа намазы укырга кирәк", - диешәләр.

Фәридә — Яңа Бүләк кызы. Бик яраткан әбисе үлгәч, гел елый, бик сагына. Әбисе төшенә кереп: "Кызым, нигә елыйсың? Мин үлмәдем, кырыеңда йөрим. Догалар өйрән, үзеңне тынычландыр. Еласаң, мине су эчендә яткырасың бит", - ди.

Камил — Сарман егете. Бик нык авырый башлый. Әнисе төшенә кереп: "Улым, әҗәтеңне түлә. Акчаң бар килеш нигә түләми йөрисең? Түләсәң, савыгырсың", - ди. Камил йокыдан уянып, бераз уйланып утыра. Әйтерсең, әнисе барысын да белеп-күреп тора. Егет тиз генә әҗәтен түләп кайта. Әнисе дөрес әйткән, Камил чыннан да озакламый савыга.

Боларны Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы дими, тагын ни дисең? Яхшы кешенең җаны яхшылык эшли, яманныкы яманлык кыла дип белеп әйткәннәр шул.

**Нәгыймә Садыйкова,**
**Тукай районы Иске Теләнче авылы.**

# Колак салсаң, үкенмәссең

◆ Мөселман халкының иң хәерлесе — ахирәт дип дөньясын онытмый, дөнья дип ахирәтен онытмый, кешеләр өстендә җәфа булып ятмый.

◆Мөселманнарның иң хәерлесе — ул мөселманнан кеше курыкмый.

◆ Иң хәерле мөэмин — алган бурычын иң яхшы рәвештә үтәүче.

◆ Иң хәерлегез — Коръән укучы, шуңа тигез итеп вакытын бүлүче, Коръән белән гамәл кылучы.

◆ Иң яхшы холыклы булган мөселманның иманы камил.

◆ Гыйлеме була торып та, аны куллана белмәгән кеше — китап төягән ишәккә охшаш.

◆ Үлчәүдә хыянәт кылган — тормышында авырлык күрер.

◆ Һәр исраф — хәрәм.

◆ Бар нәрсәне онытып дөнья кума, бервакыт дөнья сине куар.

## МИНЕМ ФИКЕР



**Таһир хәзрәт Мөхәммәтҗанов, Чаллының “Кәүсәр” мәчете Аксакаллар шурасы рәисе:**

Элек мәктәпләрдә әдәп-әхлак дәресләре бар иде, бүген исә яшьләрне капитализм кануннарына, мал табу ысулларына гына өйрәтәләр. Гаиләдә дә баланы тәртипкә өйрәтү юк. Син менә берәрсенең баласында тискәре гамәл күреп, кисәтү ясап кара, аның ата-анасы сине ун тапкыр ныграк кимсетеп ташлаячак. Шуны күреп-ишетеп торган бала тәкәббер, эгоист булмый, нинди булсын? Автобуска карт-карчык керсә, торып урын биргән яшьләр бармы хәзер? “Я тоже заплатил 22 рубля”, - ди дә, колагына наушник бауларын тыгып, янә җәелеп утыра.

Кайсы мөселман илендә үз ата-анасын, чүп урынына күреп, картлар йортына илтеп ташлаганнарын ишеткәнегез бар? Ә бездә... Әти-әни баланы кечкенә чагында ашата, киендерә, кайгырта, ахыр чиктә үзе мескен, кирәксез хәлдә шундый йортка килеп эләгә. Балага үзең ничек тәрбия бирәсең инде: әхлаклы, иманлы итеп үстерсәң, картлык көнеңдә урының түрдә була. Ә инде балаң кечкенә чагында аның туган көнен дисеңме, башка бәйрәмнәрнеме, “әйдә әле, билгеләп үтик” дип, шәраб шешәсе алып үткәреп, шундый үрнәк күрсәтеп үстерәсең икән, аның да җимешен картлык көнеңдә татыйсың: урының ишек төбендә була. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): “Бәндә баласы бу дөньяда нәрсә эшләгәнен күрмичә, бу дөньядан үтмәс”, - дигән сүзләре бар. Ягъни, һәр гамәл бумеранг шикелле. Ата-анаңны хөрмәт итеп, балаңа матур үрнәк күрсәтеп яшәсәң, олыгайгач, үзеңә дә шундый мөнәсәбәт булыр. Шуңа күрә бала тәрбияләүгә әти-әниләр җиңел генә карамасын иде.

## Ана сүзе

*(Гарәпчәдән тәрҗемә)*

Балам, бервакыт син минем картайганымны күрерсең. Картлык ямьсез булса да, сабырлык күрсәтеп, мине артык күрмәсәң иде. Ашап утырганда кулым калтырау сәбәпле ризыгым идәнгә төшсә дә, киемнәремне үзем кия алмасам да, орышма мине, балам! Исеңә төшер: хәзер эшли алмаган кайбер нәрсәләргә мин сине кайчандыр үзем өйрәткән идем. Сабыр бул, балам! Озак хәрәкәтсез ятарга туры килеп, миннән авыр ис чыкса, миннән җирәнмә, балам! Хәтерлә: син бәләкәй чакта мин сине ничек чиста һәм матур итеп киендерә идем... Ялгыш сүзләр әйтсәм, акылым җуйсам, нәрсәнедер дөрес эшләмәсәм, миннән көлмә, балам! Киресенчә, минем акылым һәм зиһенем бул, миңа ярдәм ит! Әгәр йөргәндә аякларым калтыраса, үзем генә йөри алмасам, рәнҗемә миңа, балам! Оялма, кулларыңа күтәреп ал, егылып ятарга ирек бирмә! Син тәпи йөри алмаганда, мин кешеләрдән оялмадым, сине кулымнан төшермәдем... Тормыш байлыкларына кызыкмыйча, үлемгә әзерләнүем өчен әрләмә, миңа каршы булма. Минем белән бул, балам! Үткәндәге ялгышларымны искә төшереп, мине оялтырга тырышма. Мин беркайчан да синең яхшылыктан гайре берни дә эшләмәдем. Балам, син хәзер миңа яхшылык эшләп калырга тырыш. Минем кимчелекләремне, начар гадәтләремне башкаларга күрсәтмә, яшереп кал. Моның өчен Аллаһы Тәгалә үзеңнең гөнаһларыңны да гафу итәр. Синең көлүең, елмаюың мине әле дә элеккечә шатландыра. Ташлама, балам! Син дөньяга килгән көннән бирле мин синең белән булдым. Мин үлгәндә, син янымда булсаң иде, балам!!!

### ӘДӘБИ СҮЗ

## Бүген талгын тәүге карлар яуды...

Бүген талгын тәүге карлар яуды,
Шыксыз кара дөнья булды ап-ак.
Раббым күңелемә өмет салды:
Бу матурлык дәвам итәр озак...

Йөрәгемне белән алды сафлык,
Җан төбендә яткан каралыкны
Каплап куйды гүя изге аклык,
Өстен итеп шушы ак сафлыкны.

Тәрәзәгә карап хозурланам –
Бар җиһанны акка төргән Раббым!
Карап, шөкер итәм һәм куанам,
Ә бераздан... шундый уйга калдым:

Мәшәкатьләр тәмам. Җаннар арган.
Алар шушы кышта нәрсә көтсен?
Кемдер өчен бу кар – жылы юрган,
Кемдер өчен исә – ап-ак кәфен...



Тәүге карга карап гыйбрәт алдым:
Саклар микән калеб бу аклыкны?
Шуны уйлап, ихлас дога кылдым:
Йә Илаһым! Юлдаш кыл хаклыкны...

**Ришат Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире.**

## Бергә булыйк

*Хөрмәтле укучыларыбыз!*

*“Ислам нуры” – шактый еллар дәвамында күпләрегез яратырга өлгергән бай эчтәлекле газета. Кулдан язылган хатларыгызны алып уку, андагы теләк-тәкъдимнәрегезне, җылы сүзләрегезне ишетү безнең өчен дә бик күңелле. Ике арадагы шушы элемтәләр өзелмәсен, алдагы көннәрдә дә бергә булыйк! Газета битләрендә белдерүләр, реклама текстлары да урнаштырырга мөмкин. “Ислам нуры” на почта бүлекләрендә, Татарстан буенча гына түгел, Россиянең бөтен төбәкләрендә язылырга мөмкин. Индексы – 54149.*



### Төзәтү

Газетаның 22 санындагы “Әхлак сагында” дигән язмада, техник сәбәпләр аркасында, койрыклы “к” хәрефе урынына “л” хәрефе басылып, хата киткән. Аятьне “икра бисми раббикә әлләзый халәк” дип укырга кирәк.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**25 декабрь 16 сәг.**
**фактта 25 декабрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**